**Яр Чаллы шәһәренең медицина тармагына зур өлеш керткән медицина хезмәткәрләре**

Дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе "Ф.Г.Әхмәрова исемендәге 4 нче номерлы шәһәр балалар сырхауханәсе (поликлиникасы)"



Әхмәрова Флүрә Гарип кызы (31.07.1928 – 14.12.2019) – 1983 -1998 нче елларда 4 нче номерлы шәһәр балалар поликлиникасының баш табибы, Татарстан республикасының танылган югары категорияле балалар табибы, медицина фәннәре кандидаты, Яр Чаллы шәһәренең хөрмәтле гражданины, "Иң яхшы табиб-2004" Бөтенроссия бәйгесенең "Иң яхшы тикшеренүче-табиб" номинациясендә IV дәрәҗә дипломанты, 2005 нче елның "Һөнәр-тормыш" халыкара премиясенең "Дөнья медицинасы мэтры» номинациясе лауреаты.

Казан дәүләт медицина институтын тәмамлагач, Татарстан республикасының сәламәтлек саклау министырлыгы тарафыннан Писмән шәһәренең (хәзерге Лениногорск шәһәре) район хастәханәсенә балалар табибы итеп юллана. 1977 нче елның апрель аеннан Яр Чаллы шәһәренең 4 нче номерлы шәһәр хастәханәсенең бүлек мөдире булып, ә аннары 3 нче номерлы хастаханәнең баш табибы булып эшли. Яр Чаллы шәһәренең 4 нче номерлы шәһәр балалар поликлиникасында 1983 - 1998 нче елларда – баш табиб, 1998-2006 нчы елларда оештыру-методик бүлеге мөдире булып эшли. Аның җитәкчелеге астында учреждение балалар сәламәтлеген саклауда зур уңышларга иреште, башкалар өчен үрнәк булып алдынгы тәҗрибә базасына әверелде. 1998 нче елда халыкның сәламәтлеген саклауга керткән зур өлешләре өчен 4 нче номерлы шәһәр балалар поликлиникасына Ф.Г.Әхмәрова исеме бирелде.

Ф.Г. Әхмәрова йөздән артык басма фәнни эш, Яр Чаллының сәламәтлекне саклау тарихы буенча "Шәфкатьлелек батырлыгы" дип исемләнгән ике китап нәшер итә. 1999 нчы елда медицина фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен яклый. Ф.Г. Әхмәрованың. 60 тан артык артык мактау грамоталары, 1970 нче елда "ТАССРның атказанган табибы", 1981 нче елда "КамАЗ төзелеше ударнигы", 1989 нчы елда "СССР ның сәламәтлекне саклау отличнигы", 2000 нче елда "Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданины" кебек мактаулы исемнәре бар. Ул 1966 нчы елда "Почет билгесе" ордены, 1970 нче елда "Фидакарь хезмәте өчен" , 1984 нче елда "Эш ветераны" медальләре белән бүләкләнгән.